Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 84-2 20.02.2024 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” 2023 елның 25 октябрендәге 76-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (31.01.2024 № 83-1 номерлы кертелгән үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге советы карары:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге советы «Җир салымы турында» 2023 елның 25 октябрендәге 76-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 1.2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:
« Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетыннан даими (вакыты чикләнмәгән) файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата»;

1.2. 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:
«җирле үзидарә органнары, гомуми файдаланудагы территорияләр (парклар, скверлар, ял зоналары, урман утырту һ.б.) биләгән җир кишәрлекләренә карата».

1.3. 2 статьяның 1.1 пунктчасының өченче абзацында «һәм объектлар» сүзләрен «һәм (яисә) объектлар» сүзләренә алмаштырырга, «объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлеш» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлеше» сүзләренә алмаштырырга, «объектларга һәм (яисә) объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Аграмаковка, Татар Тахталы торак пунктларында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге //spasskiy.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм https://pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырып, халыкка җиткерелергә тиеш.

Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Галәветдинова

Совет Аграмаковского сельского поселения
Республика Татарстан муниципальное образование «Аграмаковское сельское поселение» Спасского муниципального района